**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.10.2024 № 1250

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен булдыру турында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында Нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карары, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» 2020 елның 20 февралендәге 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Гражданнар оборонасы турында»Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында", Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын һәрьяклап тәэмин итүне оештыру максатларында «муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында Нигезләмәне раслау хакында» Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы боерыгы белән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү турындагы нигезләмә (1 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында коткару хезмәтләрен булдыру һәм аларның эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибе (2 нче кушымта).

2. Һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләрне башкару өчен Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының коткару хезмәтләрен булдырырга һәм аларның структурасын расларга (3нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының коткару хезмәтләре җитәкчеләренә карар рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн эчендә хезмәтнең оештыру-планлаштыру документациясен әзерләргә, килештерергә һәм билгеләнгән тәртиптә расларга.
4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында гражданнар оборонасы һәм коткару хезмәтләрен булдыру чараларын тәэмин итү турында» 19.03.2021 ел, № 269 карарын (ТР Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 30.05.2023 ел, № 527 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы

Нурлат муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә калдырырга.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин